КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 сентябрь г.Казань № 877

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 14 июнь, 265 нче; 2005 ел, 8 сентябрь, 442 нче; 2006 ел, 30 гыйнвар, 33 нче; 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2007 ел, 5 март, 70 нче; 2008 ел, 4 февраль, 61 нче; 2009 ел, 9 сентябрь, 628 нче; 2009 ел, 18 декабрь, 860 нчы; 2013 ел, 4 март, 144 нче; 2016 ел, 20 февраль, 106 нчы; 2017 ел, 3 июнь, 335 нче; 2018 ел, 1 сентябрь, 742 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 976 нчы; 2021 ел, 21 июль, 630 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

2 бүлекнең җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башка бурычлар Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән йөкләнергә мөмкин.»;

3 бүлектә:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гадәттән тыш хәлләр буенча территориаль система көчләрен һәм чараларын үстерү өлкәсендә килешенгән фәнни-техник сәясәт үткәрү буенча чаралар эшләүне һәм аларны гамәлгә ашыруны оештыра;»;

сигезенче абзацта «территориаль һәм җирле әһәмияттәге» сүзләрен «төбәк һәм муниципальара характердагы» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлектә:

алтынчы абзацны җиденче абзац дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«хәл-торышны бәяләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә юнәлдерелгән карарлар эшләү, гадәттән тыш хәлләр буенча территориаль система ихтыяҗлары, өстәмә көчләре һәм матди ресурслары, аларның көчләрен координацияләү турында актуаль мәгълүмат тапшыру максатларында Комиссиянең даими эшләүче оператив штабын төзергә, бу штабның составын, вәкаләтләрен һәм эш тәртибен билгеләргә;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы эшләвен тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеге һәм аларның функцияләренең «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» бүлеге исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин